ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

10.07.2017 г. Казань № 085-од

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларга идарәдә бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибе турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә б о е р ы к б и р әм:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларга идарәдә бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибен расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт
комитеты Рәисенең
10.07.2017 № 085-од
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларга идарәдә бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү

ТӘРТИБЕ

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларга идарәдә бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә эшләнде.

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында (алга таба – Комитет) яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба – граждан хезмәткәре), иҗтимагый оешмага, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативына, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативына, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенә (алга таба – коммерциячел булмаган оешма) идарәдә бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү процедурасын регламентлый.

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетындагы Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты Рәисе (алга таба – Рәис) үзләре өчен яллаучы вәкиле булган Татарстан Республикасы граждан хезмәткәрләренә кагыла.

2. Коммерциячел булмаган оешмаларга идарәдә бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт сорау турындагы гариза (алга таба – Гариза) граждан хезмәткәре тарафыннан әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә язма рәвештә төзелә.

3. Граждан хезмәткәре Гаризаны коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җаваплы зат Гаризаны кергән көнендә үк әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча Журналда терки.

5. Җаваплы зат Гаризаны алдан карый һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны алдан карау барышында Җаваплы зат Гариза бирүче граждан хезмәткәреннән коммерциячел булмаган оешмага идарәдә киләчәк катнашу вазыйфаларын билгеләүче язмача аңлатмалар һәм документлар соратып алырга хокуклы.

Бәяләмәдә граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларга идарәдә бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү турында яисә аннан баш тарту турында тәкъдим булырга тиеш.

6. Гаризаны теркәгән көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Җаваплы зат, Бәяләмәне һәм башка материалларны (булган очракта) кушып, граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларга идарәдә бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү турында яисә аннан баш тарту турында карар кабул итү өчен Рәискә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) тапшыра.

Рәис (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Гаризаны алган көннән ике эш көне эчендә карар кабул итә.

7. Җаваплы зат Рәис (аның вазыйфаларын башкаручы зат) карар кабул иткән көннән ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә Гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа кадрлар бүлеге һәм дәүләт хезмәте бүлеге мөһере белән таныкланган Рәис резолюциясе күчермәсен имза салдырып тапшыра. Гаризаның төп нөсхәсен, Рәис резолюциясе белән бергә, граждан хезмәткәренең шәхси эше кәгазьләренә кушып куя.

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларга идарәдә бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибенә

1 нче кушымта

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты Рәисенә

______________________________________
(Ф.Ис.Ат.ис., биләүче вазыйфасы һәм структур
______________________________________
бүлекчә, яшәү урынының адресы,
______________________________________
______________________________________
________________
телефон номеры)

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларга идарәдә бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү турында

## ГАРИЗА

Миңа идарәдә катнашырга, коллегиаль идарә органы составына керергә рөхсәт бирүегезне үтенәм (кирәгенең астына сызарга) ______________________________________
__________________(иҗтимагый оешма,
______________________________________
__________________________
торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек,
______________________________________
дача кулланучылар кооперативы, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте атамасы)

түләүсез нигездә ________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
(бердәнбер башкарма орган яисә идарәнең коллегиаль органы атамасы) сыйфатында.

____________________ ____________________ ______________________________
(дата) (имзасы) (фамилиясе, инициаллары)

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларга идарәдә бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибенә

2 нче кушымта

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмаларга идарәдә бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү турында гаризаларны теркәү

ЖУРНАЛЫ

| № т/с | Дата | Үтенечнамә бирүче Ф.Ис.Ат.ис., вазыйфасы | Үтенечнамә бирүче имзасы | Теркәүче Ф.Ис.Ат.ис. | Теркәүче имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |